| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
| 27.11.2023 | с.Старое Дрожжаное | № 475 |

«Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының муниципаль бюджет учреждениеләре тарафыннан физик һәм юридик затларга күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр күрсәтү турында» Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 28 апрелендәге 270 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының муниципаль бюджет учреждениеләре тарафыннан физик һәм юридик затларга күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр күрсәтү турында» Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 28 апрелендәге 270 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 нче кушымтада «Физик һәм юридик затларга «Җирлекара мәдәният йорты», «Җирлекара китапханә», «Туган якны өйрәнү музее» һәм «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Балалар сәнгать мәктәбе» балаларга өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учрежденияләре тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр исемлеге һәм күләме», «2014 елга «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә (башкарыла) торган түләүле хезмәтләр бәяләре турында мәгълүмат» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

*«Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы «Туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет учреждениесе* тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр бәяләре турында мәгълүмат»

| № п / п | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәясе |
|---|---|---|---|
| 1. | Керү хакы:<br><br>- 7 яшьтән 18 яшькә кадәр<br><br>- олылар<br><br>- пенсионерлар | сум. | <br><br>50<br><br>100<br><br>80 |
| 2. | Музей хезмәтләре:<br><br>- күзәтү һәм тематик экскурсияләр үткәрү<br><br>- лекцияләр үткәрү<br><br>- мәдәни-агарту чаралары үткәрү<br><br>- күргәзмә | сум. | 100-350 |
| 3. | Музейга түләүсез керү хокукына ия гражданнар категорияләре:<br><br>- гомуми авыру буенча инвалидлар<br><br>- Бөек Ватан сугышы ветераннары<br><br>- хәрби хезмәткә чакырылу буенча хәрби хезмәт үтәүче хәрбиләр<br><br>- сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар<br><br>- барлык категория гражданнар өчен һәр айның беренче сишәмбесе<br><br>- 7 яшькә кадәрге балалар<br><br>- ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар; | сум. | түләүсез |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | - балалар төркемнәрен озата баручы педагоглар һәм тәрбиячеләр<br><br>- дәүләт һәм муниципаль музей хезмәткәрләре | | түләүсез |
| 4. | - Экспозицияне фотога төшерү<br>- Мобиль (кәрәзле) телефонга төшерү | сум. | 70<br><br>30 |
| 5. | Ксерокопия ясау (1бит) | сум. | 30 |
| 6. | Методик ярдәм күрсәтү | сум. | 100 |
| 7. | Сувенир продукциясен сату | сум. | килешү бәясе буенча |

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 08 ноябрендәге 461 номерлы «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының муниципаль бюджет учреждениеләре тарафыннан физик һәм юридик затларга күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр күрсәтү турында» Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 28 апрелендәге 270 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы карарының 2 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗанов